**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6790**
**11.12.2020**

Башкарма комитетның 2013 елның 18 сентябрендәге 5663 номерлы карары белән расланган хезмәт урыныннан бирелә торган торак урынны наемга алу шартнамәсе буенча гражданнарга торак урыннар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 18 сентябрендәге 5663 номерлы карары (Башкарма комитетның 2016 елның 27 июнендәге 3272 номерлы, 2018 елның 9 ноябрендәге 6595 номерлы, 2019 елның 14 июнендәге 3047 номерлы, 2020 елның 28 октябрендәге 5615 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган хезмәт урыныннан бирелә торган торак урынны наемга алу шартнамәсе буенча гражданнарга торак урыннар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче шәхсән яки ышанычлы зат аша муниципаль хезмәт күрсәтү турында язма рәвештә гариза бирә һәм әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә (алга таба – эш кәгазьләрен алып бару идарәсе) тапшыра.

Муниципаль хезмәт күрсәтү турында электрон рәвештәге гариза Башкарма комитетка электрон почта яки Интернет-кабул итү аша җибәрелә. Электрон рәвештә кергән гаризаны теркәү билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3.3.2. Эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең гаризалар кабул итүне алып баручы белгече гамәлгә ашыра:

гариза бирүченең шәхесен ачыклауны;

гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерүне (ышаныч язуы буенча эш иткән очракта);

әлеге регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булуын тикшерүне;

тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерүне.

Кимчелекләр булмаган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итүне һәм теркәүне;

документларны кабул итү датасын күрсәтеп, гаризаның күчермәсен гариза бирүчегә бирүне.

Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, эш кәгазьләрен алып бару идарәсенең документлар кабул итүне алып баручы белгече, гариза бирүчегә гаризаны теркәү өчен каршылыклар булу турында хәбәр итә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, аңа документларны кире кайтара.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар 15 минут эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә җибәрелгән гариза яки гариза бирүчегә кире кайтарылган документлар.

3.3.3. Башкарма комитет Җитәкчесе гаризаны карап тикшерә һәм аны идарәгә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: идарәгә җибәрелгән гариза һәм документлар.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов